ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында” Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

## 1 статья

“Китапханәләр һәм китапханә эше турында” 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 1 – 2; 2004, № 2 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 3; 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Китапханәләрдән һәм китапханә хезмәте күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә тәэмин ителә. Сукырлар, начар күрүчеләр махсус дәүләт китапханәләрендә һәм һәркем файдалана алырлык башка китапханәләрдә китапханә хезмәте күрсәтелүгә һәм документларның нөсхәләрен төрле мәгълүмат туплагычларда үзләренә җайлы махсус форматларда алырга хокуклы.”;

2) 14 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

“12) Татарстан Республикасы китапханәләреннән инвалидларның файдалана алуы өчен шартларны.”.

## 2 статья

“Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында” 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $9^1$ пункт өстәргә:

“$9^1$) Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларыннан инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү;”;

2) 5 статьяда:

а) исемендә “Җирлекләрнең һәм шәһәр округларының” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлештә:

беренче абзацта “җирлекләр һәм шәһәр округлары” сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта “җирлекләр һәм шәһәр округлары” сүзләрен “муниципаль берәмлекләр” сүзләренә алмаштырырга;

в ) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

“$3^1$) җирлекләр яки шәһәр округлары милкендәге мәдәни мирас объектларыннан инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү;”.

**3 статья**

“Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында” 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяга түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

“6. Халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм дәүләт функцияләрен үтәү, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүләрнең һәм дәүләт функцияләренең федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру функцияләрен һәм дәүләт идарәсен башкаручы органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.”;

2) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

“3. Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтелә торган инфраструктура объектларыннан инвалидларның (кресло-колясkaларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

3) 4 статьяда “Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре” сүзләрен “Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре” сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

“Физик культура һәм спорт турында” 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

“4. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оештырылу-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар спорт объектларыннан инвалидларның (кресло-колясkaларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) файдалануы өчен шартлар тудыра.”.

**5 статья**

“Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында” 2010 елның 14 октябрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“$2^1$. Музейлардан инвалидларның файдалана алуы өчен, музей әйберләре һәм музей коллекцияләре белән танышу мөмкинлеген дә кертеп, шартлар тәэмин итү федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.”.

**6 статья**

“Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында” 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

“5. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм оештырылу-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалар сәламәтлек саклау өлкәсендә инфраструктура объектларыннан инвалидларның (кресло-колясkaларда йөрүче һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларны да кертеп) файдалана алуы өчен шартлар тудыра.”.

**7 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану

мөмкинлеген тәэмин итү хакында” 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 1 – 2) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

“4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларыннан күрү буенча инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итү федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.”.

**8 статья**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. Әлеге Законның инфраструктура объектларыннан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешенә кагылышлы нигезләмәләре 2016 елның 1 июленнән бары тик яңа гына файдалануга тапшырыла торган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга карата кулланыла.
3. Әлеге Законны гамәлгә ашыру максатларыннан чыгып:

1) инфраструктура объектларыннан инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар тәэмин итү максатларыннан чыгып, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары билгеләнгән эшчәнлек өлкәләрендә объектлардан һәм хезмәт күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алуы күрсәткечләрен яхшырту чараларын раслау һәм гамәлгә ашыру өчен күчеш чоры карала дип билгеләргә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республиксында җирле үзидарә органнары тарафыннан шушы органнарның дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүләре буенча административ регламентларына дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләреннән инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тәэмин итүгә карата таләпләр әлеге Закон үз көченә кергәннән соң алты ай эчендә кертелә.

4. “Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль законны һәм әлеге Законны үтәүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда күрсәтелгән максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре хисабына һәм чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 82-ТРЗ